# КАРАР

**2022 елның 24 ноябре №1**

**Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлегенең Чарлы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәсе турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 25 ноябрендә 11.00 сәгатьтә һәм 2022 елның 25 ноябрендә 13.00 сәгатьтә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлегенең Чарлы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлар); 18 яшькә кадәрге балалар тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәкләрдән; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 700 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- кышкы һәм җәйге чорда Чарлы авылы юлларын карап тоту;
- янгын куркынычсызлыгы (янгын куркынычсызлыгы рукавлары, рукавларны саклау тартмалары, авариягә каршы автоматика контроле янгын сүндерү колонкаларын сатып алу);
- төзекләндерү: агачларны (тирәк, юкә) кисү;
- юл билгеләре урнаштыру «Балалар мәйданчыгы», «Тизлекне чикләү» (;проект-смета документлары, материал сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү)
- спорт мәйданчыгына баскетбол калканнары сатып алу һәм урнаштыру;( проект-смета документлары, материал сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү)
- Чарлы авылы торак пунктына видеокүзәтү чараларын сатып алу һәм урнаштыру (проект-смета документлары, материал сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү)"

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 193 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 98.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 96 кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 2 кеше тавыш бирде.
Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлеге Чарлы авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлегенең Чарлы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлар); 18 яшькә кадәрге балалар тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәкләрдән; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 700 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- - кышкы һәм җәйге чорда Чарлы авылы юлларын карап тоту;
- янгын куркынычсызлыгы (янгын куркынычсызлыгы рукавлары, рукавларны саклау тартмалары, авариягә каршы автоматика контроле янгын сүндерү колонкаларын сатып алу);
- төзекләндерү: агачларны (тирәк, юкә) кисү;
- юл билгеләре урнаштыру «Балалар мәйданчыгы», «Тизлекне чикләү» (;проект-смета документлары, материал сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү)
- спорт мәйданчыгына баскетбол калканнары сатып алу һәм урнаштыру;( проект-смета документлары, материал сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү)
- Чарлы авылы торак пунктына видеокүзәтү чараларын сатып алу һәм урнаштыру (проект-смета документлары, материал сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү)”

«РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән дип таныргa.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Чарлы авыл жирлеге башлыгы Э.Н. Козлов